Республика Татарстан
Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423644, Менделеевский район,
с.Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы
423644, Менделеевск районы, Монашево
авылы,
Мәктәп урамы, 19 й.

тел./факс 8/85549/3-73-18,
E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.11.2024 ел № 10

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Актаҗик авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы "Монашево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 14 ноябре 10.00 сәг. гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын Менделеевск муниципаль районы, Актаҗик торак пункты, Левовозжайская ур. 13 йорт адресы буенча Актаҗик авыл клубы бинасында билгеләргә

2. "Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Актаҗик авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә Сез ризамы?" дигән сорауны расларга:

1) Актаҗик торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;
2) Актаҗик торак пунктындагы каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (чүп контейнерлары сатып алу)?»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Монашево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов